**Татарстан Республикасы**
**Югары Ослан муниципаль районы Советы**
**Карар № 35-388, 05.07 2018**

**Югары Ослан муниципаль районында дәүләт хезмәтендәге(хезмәттәге) тәртипкә таләпләрне саклау һәм ихтыяҗлар бәхәсен тәртипкә салу буенча комиссия турында Кагыйдәнамәне раслау турында**

Россия Федерациясе Хезмәт кодексы, “Россия Федерациясендә җирле үзидарәләрне оештыруның гомуми принциплары турында” 06.10.2003 № 131-ФЗ Федераль кануннары, “Ришвәтчелеккә каршы тору турында” 25нче декабрь2008нче ел №273-ФЗ, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Уставына туры китереп,

**Югары Ослан муниципаль районы Советы**
**Карар кылды:**

1. Дәүләт хезмәтендәге(хезмәттәге) тәртипкә таләпләрне саклау һәм ихтыяҗлар бәхәсен тәртипкә салу буенча комиссия турында Кагыйдәнамәне расларга.

2. Югары Ослан муниципаль районының “Югары Ослан муниципаль районының җирле үздарә органнарында муниципаль хезмәткәрләрнең дәүләт хезмәтендәге (хезмәттәге) тәртипкә таләпләрне саклау һәм ихтыяҗлар бәхәсен тәртипкә салу буенча комиссия турында Кагыйдәнамәне раслау турында” 17.11.2014нче ел №51-501 2016нчы ел карары көчен югалткан дип санарга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокук мәгълумат рәсми порталында һәм Югары Ослан муниципаль районы рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүне Югары Ослан муниципаль районы Советының хокук, тәртип саклау һәм регламент буенча даими комиссиясенә тапшырырга.

**Совет рәисе,**
**Югары Ослан**
**муниципаль районы башлыгы** **М.Г.Зиатдинов**

Югары Ослан муниципаль районы Советы
№ 35-388, 5нче июль, 2018нче ел карарына

Кушымта №1

**Дәүләт хезмәтендәге (хезмәттәге) тәртипкә таләпләрне саклау һәм ихтыяҗлар бәхәсен тәртипкә салу буенча комиссия турында**

**Кагыйдәнамә**

**1. Гомуми кагыйдәнамәләр.**

1.1. Бу Кагыйдәнамә белән “Ришвәтчелеккә каршы тору турында” 25нче декабрь, 2008нче ел, №273-ФЗ, Федераль кануны белән, “Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында” 2нче март, 2007нче ел, №25-ФЗ, Федераль кануны белән, Татарстан Республикасы муниципаль хезмәт турында 25нче июнь, 2013нче ел, №50-ЗРТ Кодексы белән, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районында дәүләт хезмәтендәге(хезмәттәге) тәртипкә таләпләрне саклау һәм ихтыяҗлар бәхәсен тәртипкә салу буенча комиссиянең эшчәнлеген оештыру тәртибе билгеләнә.

1.2. Комиссия үзенең эшчәлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль кануннарга һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокук кануннарына, Татарстан Республикасы Конституциясенә, Татарстан Республикасы кануннарына һәм башка норматив хокук кануннарга, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Уставына, әлеге Кагыйдәнамәгә һәм башка муниципаль норматив хокук актларына таянып эш итә.

1.3. Комиссиянең төп бурычы булып, төзелгән килешүләр нигезендә (алда-җирле үзидарә органнары), Югары Ослан муниципаль районы җирле үзидарә органнарына һәм Югары Ослан муниципаль районы составына кергән авыл һәм шәһәр җирле үзидарә органнарына ярдәм итү тора:

а) Муниципаль хезмәткәрләр, муниципаль хезмәткәрләрне алыштырган затлар тарафыннан чикләүләр һәм тыюлар, ихтыяҗлар бәхәсен булдырмый калу һәм тәртипкә салу турында таләпләр, шулай ук “Ришвәтчелеккә каршы тору турында” 25нче декабрь, 2008нче ел, №273-ФЗ, Федераль кануны белән, башка федераль кануннар һәм Татарстан Республикасы кануннары белән билгеләнгән үз бурычларын үтәүне тәэмин итүдә (алда -хезмәттәге тәртипкә таләпләр, яки ихтыяҗлар бәхәсен булдырмый калу);

б) Җирле үзидарә органнары карамагында булган организация (учреждение) җитәкчеләренең ихтыяҗлар бәхәсен булдырмый калу һәм тәртипкә салу турында таләпләрен үтәүне тәэмин итүдә;

в) Җирле үзидарә органында ришвәтчелекне кисәтү буенча чараларны тормышка ашыруда ярдәм итү.

1.4. Комиссия таләпләрне үтәү белән бәйле мәсьәләләрне карый:

- муниципаль хезмәткәрләргә карата хезмәтендәге тәртипкә таләпләрне саклау һәм ихтыяҗлар бәхәсен тәртипкә салу турында таләпләр;

- муниципаль вазифаларны алыштыручы затларга карата хезмәтендәге тәртипкә таләпләрне саклау һәм ихтыяҗлар бәхәсен тәртипкә салу турында таләпләр;

- Җирле үзидарә органнары карамагында булган организация (учреждение) җитәкчеләренә карата ихтыяҗлар бәхәсен булдырмый калу турында мәсьәләләрне карый.

## 2. Комиссиянең барлыкка килү тәртибе

2.1. Комиссия составы Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Советы карары белән раслана.

Комиссия комиссия рәисеннән, комиссия рәисе урынбасарыннан, сәркатип һәм комиссия әгъзаларыннан тора. Барлык комиссия әгъзалары карарлар кабул иткәндә тигез хокукка ия. Комиссия рәисе булмаганда, аның вазифаларын комиссия рәисе урынбасары башкара.

2.2. Комиссия составына керәләр:

а) Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе (комиссия рәисе), муниципаль вазифалар урынына калган затлар, җирле үзидарә органнарының кадрлар хезмәтенең ришвәтчелек һәм башка хокук бозуларга профилактика ясау чаралары өчен җаваплы хезмәтендәге зат (комиссия сәркатибе), кадрлар хезмәтеннән, юридик (хокук) бүлекчәләрдән, аның җитәкчесе тарафыннан билгеләнгән башка җирле үзидарә органнары бүлекчәләреннән муниципаль хезмәткәрләр;

б) фәнни оешмалар, профессиональ белем бирә торган оешмалар, югары белем бирә торган оешмалар һәм өстәмә профессиональ белем бирә торган оешмалар вәкиле (вәкилләре).

2.3. Җирле үзидарә органы җитәкчесе комиссия составына кертү турында карар кабул итә ала:

а) “Татарстан Республикасы Җәмәгать палатасы турында” 27нче апрель, 2017нче ел, №24-ЗРТ Татарстан Республикасы Канунының 24нче маддәсенә туры китереп җирле үзидарә органы каршында оешкан җәмәгать советы вәкилен;

б) җирле үзидарә органында оешкан ветераннар җәмәгать оешмасы, җирле үзидарә органында билгеләнгән тәртиптә эшләп килүче профсоюз оешмасы вәкилен.

2.4. Әлеге Кагыйдәнамәнең 2.2.пунктының “б” кече пунктында һәм 2.3. пунктында күрсәтелгән затлар, комиссия составына билгеләнгән тәртиптә, җирле үзидарә органы җитәкчесе соратып алуы буенча, фәнни оешмалар, профессиональ белем бирә торган оешмалар, югары белем бирә торган оешмалар һәм өстәмә профессиональ белем бирә торган оешмалар, җирле үзидарә органында оешкан ветераннар җәмәгать оешмасы, җирле үзидарә органында билгеләнгән тәртиптә эшләп килүче профсоюз оешмасы белән килешү буенча кертелә. Килешү соратып алу көненнән соң 10 көн эчендә тормышка ашырыла.

2.5. Муниципаль хезмәт вазифасын, муниципаль вазифаны башкармаган комиссия вәкилләре саны комиссиянең гомуми вәкилләре санының дүрттән бер өлешеннән ким булмаска тиеш.

2.6. Комиссия составы шундый итеп оештырыла, комиссия кабул иткән карарларга йогынты ясаучы ихтыяҗлар бәхәсенең килеп чыгу мөмкинлегенә юл куелмаска тиеш.

2.7. Комиссия утырышларында киңәш хокукы белән катнашалар:

а) Комиссия тарафыннан аңа карата дәүләт хезмәтендәге (хезмәттәге) тәртипкә таләпләрне саклау яки ихтыяҗлар бәхәсен тәртипкә салу буенча таләпләрне үтәү турындагы мәсьәлә каралган муниципаль хезмәткәрнең турыдан-туры җитәкчесе;

б) муниципаль хезмәт вазифаларын башкаручы башка муниципаль хезмәткәрләр; муниципаль вазифаларын башкаручы затлар; комиссия карый торган мәсьәләләргә аңлатма бирә алучы белгечләр; башка дәүләт органнарының, җирле үзидарә органнарының хезмәттәге затлары; кызыксңган оешмалар вәкилләре; муниципаль хезмәткәр вәкилләре, җирле үзидарә органына караган организация (учреждение) җитәкчесе муниципаль вазифасын башкаручы, аларга карата комиссия тарафыннан хезмәтендәге тәртипкә таләпләрне саклау һәм ихтыяҗлар бәхәсен тәртипкә салу буенча таләпләрне үтәү турында мәсьәләләр каралгандагы затлар,- һәр конкрет очракта кабул ителгән комиссия рәисе карары буенча комиссия утырышы көненә кадәр өч көннән дә ким булмаган вакытта, муниципаль вазифаи зат үтенече нигезендә, аңа карата комиссия тарафыннан бу мәсьәлә каралган зат, яки комиссиянең теләсә кайсы вәкиле.

2.8. Комиссия утырышы, анда комиссия әгъзаларының гомуми саныннан өчтән ике өлеше катнашса, тулы хокуклы булып санала.Утырышны муниципаль хезмәт вазифасы урынында калган комиссия әгъзалары катнашында гына үткәрү мөмкин түгел.

2.9. Комиссия әгъзасының, мәсьәләләрне тикшергәндә ихтыяҗлар бәхәсенә китерергә мөмкин булган, туры яки туры булмаган шәхси кызыксынуы барлыкка килсә, ул бу турыда утырыш башланганчы хәбәр итергә тиеш. Бу очракта комиссиянең әлеге әгъзасы бу мәсьәләне тикшергән вакытта катнаша алмый.

**3. Муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибенә таләпләрен саклау һәм ихтыяҗлар бәхәсен тәртипкә салуга кагылышлы мәсьәләләрне комиссия тарафыннан карау тәртибе**

3.1. Комиссия утырышын уздыруга нигез булып торалар:

а) җирле үзидарә органы җитәкчесенең Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы норматив хокук актларына туры китереп үткәрелгән, муниципаль хезмәткәр тапшырган мәгълуматларның дөрес һәм тулы булуын, һәм муниципаль хезмәткәрнең хезмәт тәртибенә таләпләрне саклауын тикшерү нәтиҗәләре буенча түбәндәгеләрне дәлилләүче материаллар тапшыруы:

муниципаль хезмәткәрнең, муниципаль норматив хокук актларында каралганча, керемнәре турында, мөлкәте турында һәм мөлкәт

характерындагы йөкләмәләре турында тулы яки дөрес булмаган мәгълуматлар тапшыруы;

муниципаль хезмәткәрнең хезмәт тәртибенә таләпләрне һәм ихтыяҗлар бәхәсен тәртипкә салуга таләпләрне сакламауы;

б) муниципаль норматив хокук актларында билгеләнгән тәртиптә кергән:

җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәт вазифасын башкарган, комерцияле яки комерцияле булмаган оешмада муниципаль хезмәт вазифасын башкарырга ризалык биргән, яки комерцияле яки комерцияле булмаган оешмада граждан- хокук килешүе шартларында эш башкаруга ризалык биргән гражданин мөрәҗәгате, әгәр муниципаль хезмәттән киткән көннән соң ике ел узганчы,бу оешмада муниципаль идарә итү буенча аерым функцияләр башкару хезмәттәге вазифасына керсә;

муниципаль хезмәткәрнең объектив сәбәпләр аркасында хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәт характерындагы йөкләмәләре турында мәгълуматлар тапшыра алмауы турында гариза;

муниципаль хезмәткәрнең, кулга алынган очракта, акчалары сакланган банк урнашкан чит ил дәүләте тарафыннан акчалары белән эш йөртергә салынган тыю белән бәйле булган очракта, яки аннан һәм аның хатынының, балаларының иркеннән тормаган башка очракларда, “Аерым категория затларның Россия территориясеннән читтә урнашкан банкларында счёт ачырга һәм акча, кыйммәтле әйберләр сакларга, чит ил финанс инструментларын алу һәм куллануны тыю турында” (алда- №79-ФЗ Федераль канун) 7нче май, 2013нче ел, №79-ФЗ Федераль канунны үти алмауы турында гаризасы;

муниципаль хезмәткәрнең хезмәттәге вазифасын үтәгәндә ихтыяҗлар бәхәсенә китергән һәм китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынуы килеп чыгуы турында белдерүе;

в) җирле үзидарә органы җитәчесе яки комиссиянең теләсә кайсы вәкилнең муниципаль хезмәткәрнең хезмәттәге вазифасын үтәгәндә хезмәт тәртибенә таләпләрне һәм ихтыяҗлар бәхәсен тәртипкә салуга таләпләрне саклауын булдыру, яки җирле үзидарә органында ришвәтчелекне кисәтү буенча чаралар күрүне тормышка ашыру турында язма гаризасы;

г) җирле үзидарә органы җитәчесенең, муниципаль хезмәткәрнең “Дәүләт вазифасын башкаручы затларның кереме башка затларның кереме белән туры килүен тикшерү турында” 3нче декабрь, 2012нче ел, №230- ФЗ (алда- Федераль канун №230- ФЗ) Федераль канунның 1нче бүлек, 3нче маддәсе белән каралганча, тулы яки дөрес булмаган мәгълуматлар бирүе турында раслаучы тикшерү материалларын тапшыруы;

д) “Ришвәтчелеккә каршы тору турында” 25нче декабрь, 2008нче ел, №273-ФЗ, Федераль канунының 4нче бүлеге, 12нче маддәсенә һәм Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 64.1 маддәсенә туры китереп җирле үзидарә органына комерцияле яки комерцияле булмаган оешмадан җирле үзидарә органында муниципаль хезмәт алып баручы гражданин белән килешү төзү турында; әгәр әлеге организациянең муниципаль идарәсенең

аерым функцияләре аның хезмәттәге вазифасына кермәгән булса, бу гражданинга алдарак комиссия тарафыннан әлеге оешма белән хезмәт яки граждан- хокук мөнәсәбәтләренә керү кире кагылган очракта, яки бу мәсьәлә бөтенләй каралмаган очракта, эш башкару (хезмәт күрсәтү) өчен хезмәт яки граждан- хокук килешүе төзү турында белдерү кәгазе килү.

3.2.Комиссия җинаятьләр һәм административ хокук бозулар турында белдерүләрне, шулай ук имзасыз мөрәҗәгатьләрне карамый, хезмәт дисциплинасын бозган очраклар буенча тикшерү үткәрми.

3.2.1. Әлеге Кагыйдәнамәнең 3.1. пунктының “б” кече пунктының икенче абзацында күрсәтелгән мөрәҗәгатендә күрсәтелә: фамилиясе, исеме, атасының исеме, туган көне, яшәү урыны, адресы, муниципаль хезмәттән азат ителгәннән соң соңгы ике елда башкарган вазифалары, комерцияле яки комерцияле булмаган оешманың исеме, урнашкан урыны, аның эшчәнлек төрләре, гражданинның муниципаль хезмәттәге вазифасын башкарган вакытта хезмәттәге вазифалары, комерцияле яки комерцияле булмаган оешманың муниципаль идарә итү буенча функцияләре, килешү (хезмәт яки граждан- хокук килешүе) төре, аның якынча гамәлдә булу вакыты, килешү буенча башкарылган (хезмәт күрсәтелгән) эш өчен (хезмәт күрсәткән өчен) түләү суммасы. Мөрәҗәгатьне карау “Ришвәтчелеккә каршы тору турында” 25нче декабрь, 2008нче ел, №273-ФЗ, Федераль канунының 12нче маддәсе таләпләрен исәпкә алып, мөрәҗәгатьнең мөһим булуын исәпкә алып әзерләнгән дәлилләнгән йомгак нәтиҗәләре буенча тормышка ашырыла.

3.2.2. Әлеге Кагыйдәнамәнең 3.1. пунктының “б” кече пунктының икенче абзацында күрсәтелгән мөрәҗәгать, муниципаль хезмәттән азат ителүен планлаштырган муниципаль хезмәткәр тарафыннан бирелә ала, һәм әлеге Кагыйдәнамәгә яраклаштрып, комиссия тарафыннан каралырга тиеш.

3.2.3. Әлеге Кагыйдәнамәнең 3.1. пунктының “д” кече пунктында күрсәтелгәнчә, белдерүне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча җирле үзидарә органында муниципаль хезмәт вазифасын башкарган гражданинның “Ришвәтчелеккә каршы тору турында” 25нче декабрь, 2008нче ел, №273-ФЗ, Федераль канунының 12нче маддәсе таләпләрен үтәү турында дәлилләнгән йомгак әзерләү тормышка ашырыла.

3.2.4. Белдерүне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча, әлеге Кагыйдәнамәнең 3.1. пунктының “б” кече пунктының бишенче абзацында күрсәтелгәнчә, белдерүне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча дәлилләнгән йомгак әзерләү тормышка ашырыла.

3.2.5. Мөрәҗәгатьне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча дәлилләнгән йомгак әзерләгән вакытта, әлеге Кагыйдәнамәнең 3.1. пунктының “б” кече пунктының икенче абзацында күрсәтелгәнчә, яки әлеге Кагыйдәнамәнең 3.1. пунктының “д” һәм “б”кече пунктларының бишенче абзацында күрсәтелгән белдерү кәгазе әзерләгән вакытта, комиссия мөрәҗәгатьне яки белдерү кәгазен биргән муниципаль хезмәткәр белән әңгәмә уздырырга, аннан язма рәвештә аңлату алырга хокуклы, ә шуның өчен махсус билгеләнгән вәкил, җирле үзидарә органнары җитәкчесе яки аның урынбасары, билгеләнгән тәртиптә дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына һәм кызыксынган организацияләргә сорату җибәрә ала. Мөрәҗәгать яки белдерү кәгазе, шулай

ук нәтиҗә һәм башка материаллар  мөрәҗәгать яки белдерү тапшырганнан соң җиде эш көне эчендә комиссия рәисенә тапшырыла. Сорату җибәрелгән очракта, мөрәҗәгать яки белдерү кәгазе, шулай ук нәтиҗә һәм башка материаллар  мөрәҗәгать яки белдерү тапшырганнан соң 45 көн эчендә комиссия рәисенә тапшырыла. Күрсәтелгән вакыт 30 көннән артык булмаган вакытка озынайтылырга мөмкин.

3.3. Комиссия рәисе, муниципаль норматив  хокук актларында каралган тәртиптә аңа комиссия утырышын уздырырга нигез булган мәгълумат җиткерелә икән:

а)10 көн вакыт эчендә комиссия утырышының датасы билгеләнә. Өстәвенә, комиссия утырышын уздыру вакыты, әлеге Кагыйдәнамәнең 3.3.1. һәм 3.3.2.пунктларында каралган очраклардан кала, күрсәтелгән мәгълумат җиткерелгән көннән 20 көн соңга калып билгеләнә алмый;

б) муниципаль хезмәткәрнең хезмәттәге вазифасын үтәгәндә хезмәт тәртибенә таләпләрне һәм бәхәсләр ихтыяҗын тәртипкә салу таләпләрен үтәү турында аңа карата комиссия тарафыннан тикшерелгән мәсьәлә буенча муниципаль хезмәткәрне, аның вәкилен, комиссия әгъзаларын һәм комиссия утырышында катнашан башка затларны  кергән мәгълумат һәм аны тикшергән нәтиҗәләр белән таныштыруны оештыра;

в) әлеге Кагыйдәнамәнең 2.7.пунктының “б”кече пунктында күрсәтелгән затларны комиссия утырышына чакыру турында үтенечне карый, аларны канәгатьләндерү (канәгатьләндерүне кире кагу) турында һәм комиссия утырышы барышында өстәмә материалларны карау (карауны кире кагу) турында карар кабул итә.

3.3.1. Әлеге Кагыйдәнамәнең 3.1. пунктының “б” кече пунктының өченче һәм дүртенче абзацларында күрсәтелгән гаризаларны карау буенча комиссия утырышы, керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәт характерындагы йөкләмәләре турында мәгълуматны тапшыру өчен билгеләнгән вакыты чыкканнан соң бер айдан да соңга калмыйча уздырыла.

3.3.2.Әлеге Кагыйдәнамәнең 3.1. пунктының “д” кече пунктында күрсәтелгән белдерү, гадәттә, комиссиянең чираттагы (планлы) утырышында карала.

3.4. Комиссия утырышы, гадәттә, хезмәттәге вазифасын үтәгәндә хезмәт тәртибенә таләпләрне һәм ихтыяҗлар бәхәсен тәртипкә салу таләпләрен үтәү турында аңа карата мәсьәләне тикшерү муниципаль хезмәткәр, яки җирле үзидарә органында муниципаль хезмәт вазифасын башкарган гражданин  катнашында уздырыла. Комиссия утырышында үзе катнашырга теләүе турында муниципаль хезмәткәр яки гражданин  әлеге Кагыйдәнамәнең 3.1. пунктының “б” кече пунктына туры китереп тапшырылган мөрәҗәгатьтә,  гаризада яки белдерүдә күрсәтә.

3.4.1. Комиссия утырышы муниципаль хезмәткәр яки гражданин катнашыннан башка түбәндәге очракларда узарга мөмкин:

а) әлеге Кагыйдәнамәнең 3.1. пунктының “б” кече пунктына туры китереп, тапшырылган мөрәҗәгатьтә,  гаризада яки белдерүдә комиссия утырышында муниципаль хезмәткәр яки гражданинның үзе катнашырга теләүе турында күрсәтмәсе булмаса;

б)әгәр муниципаль хезмәткәр яки гражданин комиссия утырышында үзе катнашырга теләп, тиешле дәрәҗәдә аның уздырылу вакыты һәм урыны турында аңа хәбәр җиткерелгән булып та, комиссия утырышына килмәсә.

3.5. Комиссия утырышында җирле үзидарә органнарында муниципаль вазифа башкарган муниципаль хезмәткәр яки гражданинның (аларның ризалыгы буенча), һәм башка затларның аңлатмалары тыңланыла, әлеге утырышка куелган төп материаллар, һәм шулай ук өстәмә материаллар карала.

3.6. Комиссия әгъзалары һәм аның утырышында катнашучы затлар комиссия эшләгән вакытта аларга билгеле булган мәгълуматны ачып салырга хаклы түгел.

3.7. Әлеге Кагыйдәнамәнең 3.1. пунктының “а” кече пунктының икенче абзацында күрсәтелгән мәсьәләне карау нәтиҗәләре буенча, комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) муниципаль хезмәткәр тапшырган мәгълуматлар дөрес һәм тулы икәнен билгеләү;

б) муниципаль хезмәткәр тапшырган мәгълуматлар дөрес түгел һәм(яки) тулы түгел икәнен билгеләү. Бу очракта комиссия җирле үзидарә органы җитәкчесенә муниципаль хезмәткәргә карата тиешле җаваплылык чарасын кулланырга тәкъдим итә.

3.8. Әлеге Кагыйдәнамәнең 3.1. пунктының “а” кече пунктының өченче абзацында күрсәтелгән мәсьәләне карау нәтиҗәләре буенча, комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) муниципаль хезмәткәр хезмәт тәртибенә таләпләрне һәм ихтыяҗлар бәхәсен тәртипкә салу таләпләрен үтәгән дип расларга;

б) муниципаль хезмәткәр хезмәт тәртибенә таләпләрне һәм (яки) ихтыяҗлар бәхәсен тәртипкә салу таләпләрен үтәмәгән дип расларга. Бу очракта комиссия җирле үзидарә органы җитәкчесенә муниципаль хезмәткәргә хезмәт тәртибенә таләпләрне һәм ихтыяҗлар бәхәсен тәртипкә салу таләпләрен үтәүне бозу ярамаганлыкны аңлатырга яки тиешле җаваплылык чарасын кулланырга тәкъдим итә.

3.9. Әлеге Кагыйдәнамәнең 3.1. пунктының “б” кече пунктының икенче абзацында күрсәтелгән мәсьәләне карау нәтиҗәләре буенча , комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) гражданинга, әгәр бу оешмада муниципаль идарә итү буенча аерым функцияләр башкару хезмәттәге (эш) вазифасына керсә; комерцияле яки комерцияле булмаган оешмада вазифа үтәргә яки граждан- хокук килешүе шартларында комерцияле яки комерцияле булмаган оешмада эшләргә ризалык бирергә;

б) гражданинга, әгәр бу оешмада муниципаль идарә итү буенча аерым функцияләр башкару хезмәттәге(эш) вазифасына керсә; комерцияле яки комерцияле булмаган оешмада вазифа үтәргә яки граждан- хокук килешүе шартларында комерцияле яки комерцияле булмаган оешмада эшләргә ризалыкны кире кагарга һәм кире кагуны дәлилләргә.

3.10. Әлеге Кагыйдәнамәнең 3.1. пунктының “б” кече пунктының өченче абзацында күрсәтелгән мәсьәләне карау нәтиҗәләре буенча , комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) муниципаль хезмәткәрнең хатынының(иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәт характерындагы йөкләмәләре турында мәгълуматлар тапшыра алмауы объектив һәм нигезле сәбәпләр аркасында икәнен тану;

б) муниципаль хезмәткәрнең хатынының(иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәт характерындагы йөкләмәләре турында мәгълуматлар тапшыра алмауы объектив һәм нигезле сәбәпләр аркасында булмауын һәм билгеләнгән мәгълуматларны тапшырудан читләшү чарасы икәнен тану. Бу очракта комиссия җирле үзидарә органы җитәкчесенә муниципаль хезмәткәргә карата тиешле җаваплылык чарасын кулланырга тәкъдим итә.

3.10.1. Әлеге Кагыйдәнамәнең 3.1. пунктының “г” кече пунктының өченче абзацында күрсәтелгән мәсьәләне карау нәтиҗәләре буенча, комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) №230- ФЗ Федераль канунның 1нче бүлек, 3нче маддәсенә туры китереп, муниципаль хезмәткәрнең тапшырган мәгълуматлары тулы һәм дөрес булуын тану;

б) №230- ФЗ Федераль канунның 1нче бүлек, 3нче маддәсенә туры китереп, муниципаль хезмәткәрнең тапшырган мәгълуматлары тулы һәм (яки) дөрес булмауын тану. Бу очракта комиссия җирле үзидарә органы җитәкчесенә муниципаль хезмәткәргә карата тиешле җаваплылык чарасын кулланырга тәкъдим итә һәм (яки) чыгымнарны тикшерүне тормышка ашыру нәтиҗәсендә алынган материалларны прокуратура органнарына һәм (яки) аларның компетенцияләре кысаларында, башка дәүләт органнарына җибәрергә.

3.10.2. Әлеге Кагыйдәнамәнең 3.1. пунктының “б” кече пунктының дүртенче абзацында күрсәтелгән мәсьәләне карау нәтиҗәләре буенча , комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) №79-ФЗ Федераль канун таләпләрен үтәүгә тоткарлык ясаган шартлар объектив һәм нигезле дип тану;

б) №79-ФЗ Федераль канун таләпләрен үтәүгә тоткарлык ясаган шартлар объектив һәм нигезле булмауын тану. Бу очракта комиссия җирле үзидарә органы җитәкчесенә муниципаль хезмәткәргә карата тиешле җаваплылык чарасын кулланырга тәкъдим итә.

3.10.3. Әлеге Кагыйдәнамәнең 3.1. пунктының “б” кече пунктының бишенче абзацында күрсәтелгән мәсьәләне карау нәтиҗәләре буенча , комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) муниципаль хезмәткәрнең хезмәттәге вазифасын үтәгәндә ихтыяҗлар бәхәсе булмауын;

б) муниципаль хезмәткәрнең хезмәттәге вазифасын үтәгәндә шәхси кызыксынуы ихтыяҗлар бәхәсенә китерә яки китерергә мөмкинлекне тану. Бу очракта комиссия муниципаль хезмәткәргә, һәм (яки) җирле үзидарә

органы җитәкчесенә ихтыяҗлар бәхәсен җайлау яки аларның килеп чыгуын булдырмау буенча чаралар күрергә тәкъдим итә;

в) муниципаль хезмәткәр ихтыяҗлар бәхәсен җайлау турында таләпләрне үтмәгән дип табырга. Бу очракта комиссия җирле үзидарә органы җитәкчесенә муниципаль хезмәткәргә карата тиешле җаваплылык чарасын кулланырга тәкъдим итә.

3.11. Әлеге Кагыйдәнамәнең 3.1. пунктының “а”, “б”,”г”,”д” кече пунктларында күрсәтелгән мәсьәләне карау нәтиҗәләре буенча, моңа нигез булганда, комиссия әлеге Кагыйдәнамәнең 3.7.-3.10,3.10.1-3.10.3 һәм 3.11.1 пунктлары белән каралмаган, башка карар кабул итә ала. Мондый карарны кабул итү сәбәпләре һәм дәлилләре комиссия утырышының беркетмәсендә күрсәтеләргә тиеш.

3.11.1. Әлеге Кагыйдәнамәнең 3.1. пунктының “д” кече пунктының бишенче абзацында күрсәтелгән мәсьәләне карау нәтиҗәләре буенча, җирле үзидарә органында муниципаль хезмәт вазифасын башкарган гражданинга карата комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) гражданинга, әгәр бу оешмада муниципаль идарә итү буенча аерым функцияләр башкару хезмәттәге (эш) вазифасына керсә, комерцияле яки комерцияле булмаган оешмада вазифа үтәргә яки граждан - хокук килешүе шартларында комерцияле яки комерцияле булмаган оешмада эшләргә ризалык бирергә;

б) килешү буенча башкарылган комерцияле яки комерцияле булмаган оешмада вазифа һәм (яки) комерцияле яки комерцияле булмаган оешмада эш оештыру (хезмәт күрсәтү) “Ришвәтчелеккә каршы тору турында” 25нче декабрь, 2008нче ел, №273-ФЗ, Федераль канунының 12нче маддәсе таләпләрен боза. Бу очракта комиссия җирле үзидарә органы җитәкчесенә прокуратура органнарына һәм белдергән оешмага күрсәтелгән хәлләр турында хәбәр итергә тәкъдим итә.

3.12. Әлеге Кагыйдәнамәнең 3.1. пунктының “в” кече пунктында күрсәтелгән мәсьәләне карау нәтиҗәләре буенча, комиссия тиешле карар кабул итә.

3.13. Комиссия карарын үтәү өчен, билгеләнгән тәртиптә җирле үзидарә органы җитәкчесе карап чыгуына тәкъдим ителәчәк, җирле үзидарә органнарының норматив хокук актлары, җирле үзидарә органы җитәкчесенең йөкләмә һәм карарлары проектлары әзерләнә ала.

3.14. Әлеге Кагыйдәнамәнең 3.1. пунктында күрсәтелгән сораулар буенча карарлар утырышта катнашучы комиссия әгъзаларының күпчелек тавыш белән яшерен тавыш бирү юлы белән (әгәр комиссия башка карар кабул итмәсә) кабул ителә.

3.15. Комиссия карарлары аның утырышында катнашкан комиссия әгъзалары имзалаган беркетмә белән рәсмиләштерелә. Әлеге Кагыйдәнамәнең 3.1. пунктының “б” кече пунктының икенче абзацында күрсәтелгән мәсьәләне карау нәтиҗәләре буенча кабул ителгән карарлардан тыш, күрсәтелгән комиссия карарлары җирле үзидарә органы җитәкчесе өчен тәкъдим итү характерында була. Әлеге Кагыйдәнамәнең 3.1. пунктының

“б” кече пунктының икенче абзацында күрсәтелгән мәсьәләне карау нәтиҗәләре буенча кабул ителгән карарлар мәҗбүри характерда була.

3.16. Комиссия утырышы беркетмәсендә күрсәтелә:

а) комиссия утырышы датасы, утырышта катнашкан комиссия әгъзалары һәм башка затларның фамилиясе, исеме, атасының исеме;

б) аңа карата, хезмәт тәртибенә таләпләрне саклау һәм ихтыяҗлар бәхәсен тәртипкә салу таләпләрен үтәү турында мәсьәләләрне тикшергәндә, муниципаль хезмәткәрнең вазифасын, фамилиясен, исемен, атасының исемен күрсәтеп, комиссия утырышында каралган һәр мәсьәләнең тәгъбире;

в) муниципаль хезмәткәргә карата күрсәтелгән дәгъвалар, аларга нигезләнгән материаллар;

г) муниципаль хезмәткәрнең һәм башка затларның күрсәтелгән төп дәгъвалар буенча аңлатма эчтәлеге;

д) утырышта чыгыш ясаган затларның фамилиясе, исеме, атасының исеме һәм аларның чыгышларының кыскача эчтәлеге;

е) комиссия утырышын үткәрергә нигез булган мәгълумат чыганагын, мәгълуматның җирле үзидарә органнарына җиткерелгән вакыты;

ж) башка мәгълуматлар;

з) тавыш бирү нәтиҗәләре;

и) карар һәм аны кабул итүнең нигезе.

3.17. Аның карары белән килешмәгән комиссия әгъзасы, комиссия утырышы беркетмәсенә теркәлергә һәм муниципаль хезмәткәр танышырга тиешле фикерен, язма формада җиткерергә хокуклы.

3.18. Комиссия утырышы беркетмәсенең күчерелмәсе утырыштан соң 7 көн эчендә җирле үзидарә органы җитәкчесенә тулысынча яки аннан өземтә итеп - муниципаль хезмәткәргә, шулай ук комиссия карары буенча – башка кызыксынган затларга җибәрелә.

3.19. Җирле үзидарә органы җитәкчесе комиссия утырышы беркетмәсен карап чыгарга тиеш һәм үзенең компетенцияләре кысаларында, муниципаль хезмәткәргә карата Россия Федерациясе норматив хокук актларында күрсәтелгән җаваплылык чараларын күрү турында карар кабул иткәндә, кертелгән киңәшләрне исәпкә алырга хокуклы, шулай ук ришвәтчелеккә каршы торуны оештыру буенча башка мәсьәләләрне исәпкә алырга хокуклы. Комиссия тәкъдимнәрен карау һәм кабул ителгән карар турында җирле үзидарә органы җитәкчесе язма рәвештә, аңа утырыш беркетмәсе тапшырылган көннән соң, бер ай эчендә комиссияне таныштыра. Җирле үзидарә органы җитәкчесе карары комиссиянең якындагы утырышында укып чыгыла һәм тикшермичә кабул ителә.

3.20. Комиссия тарафыннан муниципаль хезмәткәрнең гамәлләрендә (гамьсезлегендә) дисциплинар хата билгеләре ачыкланган очракта, бу турыда мәгълумат, муниципаль хезмәткәргә карата, Россия Федерациясе норматив хокук актларында күрсәтелгән җаваплылык чараларын күрү буенча мәсьәләне чишү өчен, җирле үзидарә органы җитәкчесенә тапшырыла.

3.21. Комиссия тарафыннан муниципаль хезмәткәрнең административ хокук бозулар билгеләре булган гамәлләре (гамьсезлек фактлары), яки җинаять эшләре ачыкланган очракта, комиссия рәисе әлеге гамәлләр

(гамьсезлек фактлары) булу турында һәм бу фактны раслаучы документларны 3 көн эчендә хокук саклау органнарына, ә кирәк булса - кичекмәстән тапшырырга тиеш.

3.22. Комиссия утырышы беркетмәсенең күчерелмәсе яки аның өземтәсе, аңа карата, хезмәт тәртибенә таләпләрне саклау һәм(яки) ихтыяҗлар бәхәсен тәртипкә салу таләпләрен үтәү турында мәсьәләләр тикшерелгән, муниципаль хезмәткәрнең шәхси делосына теркәлеп куела.

3.22.1. Комиссия утырышының, комиссия сәркатибе имзасы һәм җирле үзидарә органы мөхере белән расланган өземтәсе, аңа карата әлеге кагыйдәнамәнең 3.1. пунктының "б" кече пунктының икенче абзацында күрсәтелгән мәсьәлә каралган җирле үзидарә органында муниципаль хезмәт башкарган гражданинга кул куйдырып тапшырыла яки әлеге комиссия утырышы үткәрелгәннән соң бер эш көненнән дә соңга калмыйча белдерү кәгазе белән заказной хат белән мөрәҗәгатендә күрсәтелгән адрес буенча җибәрелә.

3.23.Оештыру-техник һәм комиссия эшчәнлеген документ белән тәэмин итү, шулай ук комиссия әгъзаларына көн тәртибенә куелган сораулар, дата, вакыт һәм утырыш үткәрү урыны турында хәбәр итү, комиссия әгъзаларын комиссия утырышында тикшерелергә тәкъдим ителгән материаллар белән таныштыру сәркатиб тарафыннан башкарыла.

**4.Муниципаль вазифаларны башкаручы затларның дәүләт хезмәтендәге тәртипкә таләпләрен саклау һәм ихтыяҗлар бәхәсен тәртипкә салуга кагылышлы мәсьәләләрне комиссия тарафыннан карау тәртибе**

4.1. Комиссия утырышын уздыруга нигез булып торалар:

а) муниципаль вазифаларны башкаручы затның дәүләт хезмәтендәге тәртипкә таләпләрне бозуы турында кергән материаллар нигезендә комиссия рәисенең кабул иткән карары;

б) хезмәттәге вазифаларны башкарганда ихтыяҗлар бәхәсенә китерүче яки китерергә мөмкин булган шәхси кызыксыну килеп чыгуы турында комиссиягә килгән белдерү кәгазе, шулай ук мотивлаштырылган нәтиҗә һәм башка материаллар.

4.2. Комиссия тарафыннан әлеге кагыйдәнамәнең 4.1. пунктының "б" кече пунктында күрсәтелгән белдерүне карап чыгу тормышка ашырыла, һәм аны карап чыгуның нәтиҗәләре буенча мотивлаштырылган нәтиҗә әзерләнә.

4.2.1. Әлеге Кагыйдәнамәнең 4.2. пунктында каралган мотивлаштырылган нәтиҗәне әзерләгән вакытта, Татарсан Республикасының Югары Ослан муниципаль районы Башлыгы кушуы буенча, комиссия билгеләнгән тәртиптә әлеге Кагыйдәнамәнең 4.1. пунктына туры китереп, белдерү кәгазе тапшырган заттан кирәкле аңлармаларны алырга хокуклы, ә Татарстан Республикасының Югары Ослан муниципаль районы Башлыгы билгеләнгән тәртиптә федераль дәүләт органнарына, Татарстан Республикасы дәүләт власте органнарына һәм Россия Федерациясенең башка субъектларна, җирле үзидарә органнарына һәм кызыксынган оешмаларга сорату җибәрә ала.

Белдерү кәгазе, шулай ук нәтиҗә һәм башка материаллар гариза яки белдерү кәгазе тапшырылганнан соң җиде эш көне эчендә комиссия рәисенә тәкъдим ителә.

Сорату җибәргән очракта белдерү кәгазе, шулай ук нәтиҗә һәм башка материаллар, белдерү кәгазе тапшырылганнан соң 45 көн эчендә, комиссиия рәисенә тәкъдим ителә. Билгеләнгән вакыт озынайтлырга мөмкин, ләкин 30 көннән дә артмаска тиеш.

4.3. Әлеге Кагыйдәнамәнең 4.1. пунктында күрсәтелгән мәсьәләләрне карау буенча комиссия утырышын үткәрү вакыты һәм үткәрү урыны комиссия рәисе тарафыннан билгеләнә

4.4. Комиссия сәркатибе комиссия утырышына карап чыгуга куелачак сорауларны әзерләүне тәэмин итә, шулай ук комиссия әгъзаларына һәм муниципаль вазифалар башкаручы башка затларга комиссия утырышының көн тәртибенә кертелгән сораулар турында, датасы, вакыты һәм утырышны үткәрү урыны турында, утырыш булыр алдыннан җиде эш көненнән дә соңга калмыйча хәбәр итүне оештыра.

4.5. Әгәр комиссия утырышында, дәүләт хезмәтендәге тәртипкә таләпләрен саклау яки ихтыяҗлар бәхәсен тәртипкә салуга кагылышлы мәсьәләләр комиссия әгъзаларының берсенә карата каралган очракта, күрсәтелгән комиссия әгъзасы Әлеге Кагыйдәнамәнең 4.9.,4.10. пунктларына туры китереп, карар кабул иткәндә тавыш бирү хокукына ия була алмый.

4.6. Комиссия утырышы, әлеге Кагыйдәнамәнең 4.1. пунктына туры китереп, гадәттә белдерү кәгазен тапшырган зат катнашында уза. Комиссия утырышында үзе катнашырга теләүе турында белдерү кәгазен тапшырган зат белдерү кәгазендә күрсәтә.

4.6.1. Комиссия утырышы, әлеге Кагыйдәнамәнең 4.1. пунктына туры китереп, белдерү кәгазен тапшырган зат катнашыннан башка түбәндәге очракта узарга мөмкин:

а) комиссия утырышында үзе катнашырга теләүе турында, белдерү кәгазен тапшырган зат, белдерү кәгазендә күрсәтмәгән булса;

б) әгәр, комиссия утырышында үзе катнашырга теләүе турында белдерү кәгазен тапшырган һәм тиешле тәртиптә аның үткәрү вакыты һәм урыны турында хәбәр ителгән зат, комиссия утырышына килмәсә.

4.7.Комиссия утырышында, комиссия рәисе билгеләгән тәртиптә, муниципаль вазифалар башкаручы затның аңлатмалары тыңланыла, һәм утырышның көн тәртибенә кертелгән сорауларга кагылышлы материаллар карала. Комиссия утырышында комиссия әгъзаларының, муниципаль вазифалар башкаручы затның үтенече буенча, башка затлар тыңланылырга һәм алар тәкъдим иткән материаллар каралырга мөмкин.

4.8. Комиссия әгъзалары һәм аның утырышында катнашучы затлар, комиссия утырышы барышында аларга билгеле булган мәгълуматларны ачып салырга хокуклы түгел.

4.9. Әлеге Кагыйдәнамәнең 4.1. пунктының “а” кече пунктында күрсәтелгән мәсьәләне карау нәтиҗәләре буенча, комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) карала торган очракта, муниципаль вазифалар башкаручы затның, дәүләт хезмәтендәге тәртипкә таләпләрен бозу очраклары юк икәнен ачыклау;

б) карала торган очракта, муниципаль вазифалар башкаручы затның, дәүләт хезмәтендәге тәртипкә таләпләрен бозу очраклары бар икәнен ачыклау.

4.10. Әлеге Кагыйдәнамәнең 4.1. пунктының “б” кече пунктында күрсәтелгән мәсьәләне карау нәтиҗәләре буенча, комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) белдерү кәгазен тапшыручы затның хезмәттәге вазифаларны башкарганда ихтыяҗлар бәхәсе юк икәнен тану;

б) белдерү кәгазен тапшыручы затның хезмәттәге вазифаларны башкарганда шәхси кызыксынуы ихтыяҗлар бәхәсенә китерә яки китерергә мөмкин булуын тану. Бу очракта комиссия белдерү кәгазен тапшыручы затка ихтыяҗлар бәхәсен тәртипкә салырга яки булдырмый калу чараларын күрергә тәкъдим итә;

в) белдерү кәгазен тапшыручы затның ихтыяҗлар бәхәсен тәртипкә салу таләпләре үтәлмәгән дип табарга. Кабул ителгән карар турында комиссия рәисе яки комиссия сәркатибе җирле үзидарә органы хезмәтендәге затына яки Россия Федерациясе кануннары белән каралган юридик җаваплылык чараларын күрергә тиешле оешмага хәбәр итергә тиеш.

4.11. Комиссия тарафыннан муниципаль вазифалар башкаручы затның админстратив хокук бозу билгеләре булган гамәлләр (гамьсезлекләре) башкару очраклары яки җинаять эшләре ачыкланса, комиссия сәркатибе комиссия рәисе кушуы буенча күрсәтелгән гамәлләр (гамьсезлекләр) башкарылу очраклары турында мәгълуматны һәм бу фактны раслаучы документларны хокук саклау оешмаларына өч көн эчендә, ә кирәк булганда кичектерүсез җибәрә.

4.12. Комиссия карарлары коллегиаль утырышта катнашучы комиссия әгъзаларының күпчелек тавыш бирү юлы белән коллегиаль кабул ителә. Тавышлар тигез булганда, комиссия рәисе тавышы хәл иткеч була.

4.13. Комиссия карары комиссия рәисе һәм комиссия сәркатибе имзалаган беркетмә белән рәсмиләштерелә.

4.13.1. Әгәр әлеге Кагыйдәнамәнең 4.1. пунктының “б” кече пунктында каралган белдерү кәгазендә аларны тәкъдим иткән затларның үзләре комиссия утырышында катнашырга теләүләре турында күрсәтелмәгән булса, комиссия рәисе карары буенча әлеге Кагыйдәнамәнең 4.1. пунктының “б” кече пунктында каралган мәсьәлә буенча тавыш бирү читтән торып комиссия әгъзаларына сорау алу кәгазьләре, шулай ук башка материаллар җибәрү юлы белән үткәрелергә мөмкин.

Сорау алу кәгазен тутырган вакытта комиссия әгъзасы комиссия тәкъдим иткән карарга карата, аңа каршы яки аны яклап тавыш биреп, һичшиксез үзенең фикерен белдерергә тиеш. Комиссия әгъзасы имзалаган сорау алу кәгазе аны алганнан соң өч эш көненнән дә соңга калмыйча комиссиягә җибәрелә. Читтән торып тавыш бирү нәтиҗәләре буенча кабул ителгән комиссия карары әлеге Кагыйдәнамәнең 4.14. пункты таләпләренә

туры китереп беркетмә белән рәсмиләштерелә һәм комиссия әгъзаларына һәм кызыксынган затларга беркетмә имзаланганнан соң җиде эш көне эчендә җибәрелә.

4.14.Комиссия утырышы беркетмәсендә күрсәтелә:

а) комиссия утырышы датасы, комиссия әгъзаларының һәм утырышта катнашкан башка затларның фамилияләре, исемнәре, аталарының исемнәре;

б) муниципаль вазифалар башкаручы затка карата комиссия утырышында каралган һәрбер мәсьәләнең формулировкасы, аның фамилиясе, исеме, атасының исеме, вазифасы;

в)Комиссия утырышын үткәрү өчен нигез булган мәгълуматның чыганагы һәм мәгълуматның кергән вакыты;

г) муниципаль вазифа башкаручы затның һәм башка затларның каралган төп мәсьәләләр буенча аңлатмалары эчтәлеге;

д) утырышта чыгыш ясаган затларның фамилияләре, исемнәре, аталарының исемнәре һәм аларның чыгышларының кыскача эчтәлеге;

е) башка мәгълуматлар;

ж) тавыш бирү нәтиҗәләре;

з) комиссия карары һәм аны кабул итүнең дәлиле.

4.15. Кабул ителгән карар белән килешмәгән комиссия әгъзасы, язма рәвештә һичшиксез комиссия утырышы беркетмәсенә теркәп куерга тиеш булган, үзенең аерым фикерен җиткерергә тиеш.

4.16. Комиссия карарыннан өземтә, мәсьәләләр аңа карата тикшерелгән муниципаль вазифа башкаручы затка җибәрелә, шулай ук, аны билгеләргә (сайларга, расларга) вәкиллек иткән хезмәттәге затка (җирле үзидарә органына) комиссия утырышы имзлаган беркетмә биш эш көне эчендә җибәрелә.

4.17. Комиссия карарына Россия Федерациясе кануннары белән билгеләнгән тәртиптә шикаять бирелә ала.

## 5. Комиссия тарафыннан муниципаль учреждение (оешма, предприятие) җитәкчесенең хезмәттәге вазифаларны башкарганда шәхси кызыксынунының килеп чыгуы ихтыяҗлар бәхәсенә китерә яки китерергә мөмкин булуы турында белдермәләрен карау тәртибе

5.1. Комиссия утырышын уздыруга, учреждение (оешма, предприятие) җитәкчесенән хезмәттәге вазифаларны башкарганда шәхси кызыксынунының килеп чыгуы ихтыяҗлар бәхәсенә (алда - белдермә) китерә яки китерергә мөмкин булуы турында белдермә килүе, шулай ук мотивлашкан нәтиҗә һәм башка материаллар җирлек булып тора.

5.2. Комиссия тарафыннан әлеге Кагыйдәнамәнең 5.1. пунктында күрсәтелгән белдермәне алдан карап чыгу тормышка ашырыла, һәм карап чыгу нәтиҗәләре буенча мотивлашкан нәтиҗә әзерләнә.

5.3. Әлеге Кагыйдәнамәнең 5.2. пункты белән күздә тотылган мотивлашкан нәтиҗәне әзерләгәндә комиссия билгеләнгән тәртиптә әлеге Кагыйдәнамәнең 5.1. пунктына туры китереп белдерү кәгазе тапшырган затлардан кирәкле аңлатмаларны алырга хокуклы, ә оешманың (учреждениенең) оештыручысы булган җирле үзидарә органы җитәкчесе яки

моның өчен махсус билгеләнгән аның урынбасары, билгеләнгән тәртиптә федераль дәүләт органнарына, Татарстан Республикасы дәүләт власте органнарына һәм башка Россия Федерациясе субъектларына, җирле үзидарә органнарына һәм кызыксынган оешмаларга сорату җибәрә ала.

Белдерү кәгазе, шулай ук нәтиҗә һәм башка материаллар гариза яки белдерү кәгазе тапшырылганнан соң җиде эш көне эчендә комиссия рәисенә тапшырылалар. Сорату җибәргән очракта, белдерү кәгазе, шулай ук нәтиҗә һәм башка материаллар комиссия рәисенә гариза яки белдерү кәгазе тапшырылганнан соң 45 көн эчендә тапшырылалар. Билгеләнгән вакыт озынайтылырга мөмкин, ләкин 30 көннән дә артмаска тиеш.

5.4. Әлеге Кагыйдәнамәнең 5.1. пунктында күрсәтелгән мәсьәләне карау күздә тотылган комиссия утырышының үткәрү датасы, һәм аны үткәрү урыны комиссия рәисе тарафыннан билгеләнә.

5.5. Комиссия сәркатибе комиссия утырышына карап чыгуга куелачак сорауларны әзерләүне тәэмин итә, шулай ук комиссия әгъзаларына һәм муниципаль вазифалар башкаручы затка комиссия утырышының көн тәртибенә кертелгән сораулар турында, датасы, вакыты һәм утырышны үткәрү урыны турында, утырыш булыр алдыннан җиде эш көненнән дә соңга калмыйча хәбәр итүне оештыра.

5.6. Комиссия утырышы, әлеге Кагыйдәнамәнең 5.1. пунктына туры китереп, гадәттә белдерү кәгазен тапшырган зат катнашында уза. Комиссия утырышында үзе катнашырга теләүе турында белдерү кәгазен тапшырган зат белдерү кәгазендә күрсәтә.

5.6.1. Комиссия утырышы, әлеге Кагыйдәнамәнең 5.1. пунктына туры китереп, белдерү кәгазен тапшырган зат катнашыннан башка түбәндәге очракта узарга мөмкин:

а) комиссия утырышында үзе катнашырга теләүе турында, белдерү кәгазен тапшырган зат, белдерү кәгазендә күрсәтмәгән булса;

б) әгәр, комиссия утырышында үзе катнашырга теләүе турында белдерү кәгазен тапшырган һәм тиешле тәртиптә аның үткәрү вакыты һәм урыны турында хәбәр ителгән зат, комиссия утырышына килмәсә.

5.7. Комиссия утырышында, комиссия рәисе билгеләгән тәртиптә, учреждение (оешма, предприятие) җитәкчесенең аңлатмалары тыңланыла, һәм утырышның көн тәртибенә кертелгән сорауларга кагылышлы материаллар карала. Комиссия утырышында комиссия әгъзаларының, учреждение (оешма, предприятие) җитәкчесенең үтенече буенча, башка затлар тыңланылырга һәм алар тәкъдим иткән материаллар каралырга мөмкин.

5.8. Комиссия әгъзалары һәм аның утырышында катнашучы затлар, комиссия утырышы барышында аларга билгеле булган мәгълуматларны ачып салырга хокуклы түгел.

5.9. Әлеге Кагыйдәнамәнең 5.1. пунктында күрсәтелгән мәсьәләне карау нәтиҗәләре буенча, комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) белдерү кәгазен тапшырган затның хезмәттәге вазифаларын башкарган вакытта ихтыяҗлар бәхәсе юк дип табарга;

б) белдерү кәгазен тапшырган затның хезмәттәге вазифаларны башкарган вакытта шәхси кызыксынуның килеп чыуы ихтыяҗлар бәхәсенә китерә яки китерергә мөмкин дип табарга. Бу очракта комиссия белдерү кәгазен тапшыручы затка ихтыяҗлар бәхәсен тәртипкә салырга яки булдырмый калу чараларын күрергә тәкъдим итә;

в) белдерү кәгазен тапшыручы затның ихтыяҗлар бәхәсен тәртипкә салу таләпләре үтәлмәгән дип табарга.

Бу очракта Комиссия тәкъдим итә:

Оешманың (учреждениенең) оештыручысы булган җирле үзидарә органы җитәкчесенә учреждение (оешма, предприятие) җитәкчесенә карата конкрет җаваплылык чарасын күрергә; белдерү кәгазен тапшыручы затка ихтыяҗлар бәхәсен тәртипкә салу чараларын күрергә тәкъдим итә.

5.10. Комиссия тарафыннан учреждение (оешма, предприятие) җитәкчесенең админстратив хокук бозу билгеләре булган гамәлләр (гамьсезлекләре) башкару очраклары яки җинаять эшләре ачыкланса, комиссия сәркатибе комиссия рәисе кушуы буенча күрсәтелгән гамәлләр (гамьсезлекләр) башкарылу очраклары турында мәгълуматны һәм бу фактны раслаучы документларны хокук саклау оешмаларына өч көн эчендә, ә кирәк булганда кичектерүсез җибәрә.

5.11. Комиссия карарлары коллегиаль утырышта катнашучы комиссия әгъзаларының күпчелек тавыш бирү юлы белән коллегиаль кабул ителә. Тавышлар тигез булганда, комиссия рәисе тавышы хәл иткеч була.

5.12. Комиссия карары комиссия рәисе һәм комиссия сәркатибе имзалаган беркетмә белән рәсмиләштерелә.

5.13. Әгәр әлеге Кагыйдәнамәнең 5.1. пунктында каралган белдерү кәгазендә аларны тәкъдим иткән затларның үзләре комиссия утырышында катнашырга теләүләре турында күрсәтелмәгән булса, комиссия рәисе карары буенча әлеге Кагыйдәнамәнең 5.1. пунктында каралган мәсьәлә буенча тавыш бирү читтән торып комиссия әгъзаларына сорау алу кәгазьләре, шулай ук башка материаллар җибәрү юлы белән үткәрелергә мөмкин.

Сорау алу кәгазен тутырган вакытта комиссия әгъзасы комиссия тәкъдим иткән карарга карата, аңа каршы яки аны яклап тавыш биреп, һичшиксез үзенең фикерен белдерергә тиеш. Комиссия әгъзасы имзалаган сорау алу кәгазе аны алганнан соң өч эш көненнән дә соңга калмыйча комиссиягә җибәрелә. Читтән торып тавыш бирү нәтиҗәләре буенча кабул ителгән комиссия карары әлеге Кагыйдәнамәнең 4.14. пункты таләпләренә туры китереп беркетмә белән рәсмиләштерелә һәм комиссия әгъзаларына һәм кызыксынган затларга беркетмә имзаланганнан соң җиде эш көне эчендә җибәрелә.

5.14. Комиссия утырышы беркетмәсендә күрсәтелә:

а) комиссия утырышы датасы, комиссия әгъзаларының һәм утырышта катнашкан башка затларның фамилияләре, исемнәре, аталарының исемнәре;

б) учреждение (оешма, предприятие) җитәкчесенә карата комиссия утырышында каралган һәрбер мәсьәләнең формулировкасы, аның фамилиясе, исеме, атасының исеме, вазифасы;

в) Комиссия утырышын үткәрү өчен нигез булган мәгълуматның чыганагы һәм мәгълуматның кергән вакыты;

г) учреждение (оешма, предприятие) җитәкчесенең һәм башка затларның каралган төп мәсьәләләр буенча аңлатмалары эчтәлеге;

д) утырышта чыгыш ясаган затларның фамилияләре, исемнәре, аталарының исемнәре һәм аларның чыгышларының кыскача эчтәлеге;

е) башка мәгълуматлар;

ж) тавыш бирү нәтиҗәләре;

з) комиссия карары һәм аны кабул итүнең дәлиле.

5.15. Кабул ителгән карар белән килешмәгән комиссия әгъзасы, язма рәвештә һичшиксез комиссия утырышы беркетмәсенә теркәп куерга тиеш булган, үзенең аерым фикерен җиткерергә тиеш.

5.16. Комиссия карарыннан өземтә, мәсьәләләр аңа карата тикшерелгән учреждение (оешма, предприятие) җитәкчесенә җибәрелә, шулай ук, оешманың (учреждениенең, предприятинең) оештыручысы булган җирле үзидарә органына, комиссия утырышы имзалаган беркетмә биш эш көне эчендә җибәрелә.

5.17. Комиссия карарына Россия Федерациясе кануннары белән билгеләнгән тәртиптә шикаять бирелә ала.

**Совет рәисе,**
**Югары Ослан**
**муниципаль районы башлыгы** **М.Г.Зиатдинов**